**ГЛАВА ШАХМАЙКИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ НОВОШЕШМИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

Ул. Центральная, д.45Б,
с. Шахмайкино,423183

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЯҢА ЧИШМӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ШАХМАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

Үзәк урам, 45Б
Шахмай авылы,423183

тел.: (8-84348) 3-84-96, факс: (8-84348) 3-84-46, Shah.Nsm@tatar.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

2022 елның 06 октябре № 1

«Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләп кую турында»

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге муниципаль берәмлеге Уставының 81 статьясы, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы

КАРАР БИРӘ:

1. 2022 елның 17 октябрендә «Нур» кибете янында (Үзәк ур., 75) Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар Җыенының беренче этабын 09 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. 2022 елның 17 октябрендә Шахмай урта мәктәбе янында (Үзәк ур., 38 йорт) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. 2022 елның 17 октябрендә Шахмай авыл мәдәният йортында (Үзәк ур., 45) Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
4. Халык җыенын үткәрү өчен Шахмай авылында яшәүчеләр исемлеген аеруны сайлау тәртибен вакытлыча билгеләр буенча башкарырга кирәк.
5. Халык җыенын үткәрү һәм оештыру эшләре Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районы Шахмай авыл җирлеге башлыгы белән тәэмин ителә.
6. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

«Сез 2023 елда Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авыл җирлеге Шахмай авылында яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертү турында килешәсезме, моннан тыш, көндезге уку формасы буенча укучы студентлардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, сугыш хәрәкәтләре ветераннарыннан һәм Россия Федерациясе Кораллы Көчләренә мобилизацияләнгән гражданнар һәм аларның гаилә әгъзалары, 75 яшьтән өлкәнрәк ялгыз яшәүче 1 Төркем инвалидларыннан һәм алынган җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкаруга тотарга:

- Чишмә, Яңа, Х. Хәйруллин, Үзәк урамнарына, тыкрыклага, вак таш салу буенча материал сатып алу, ташу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү) авыл эчендәге юлларны ремонтлау;
- юлларны кардан чистарту (килешү буенча эшләр өчен түләү);
- җәйге чорда территорияне чабу (ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);
- зират территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен һәм үсемлекләрне юк итү өчен акча алу, чабу, төзелеш материаллары сатып алу, коры агачларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү);
- «Наил бабай чишмәсе» территориясен төзекләндерү (чүп үләннәрен һәм үсемлекләрне юк итү өчен акча алу, чабу, коры агачларны кисү, килешү буенча эш өчен түләү).

«ӘЙЕ» «ЮК».».

7. Әлеге карарны гражданнар җыены этапларын үткәрү көненә 10 көннән дә соңга калмыйча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында» Интернет «мәгълүмат-телекоммуцион челтәрендә бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә): http://pravo.tatarstan.ru., Яңа Чишмә муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә: http://novosheshminsk.tatarstan.ru/, Татарстан Республикасы Яңа Чишмә муниципаль районының Шахмай авылындагы мәгълүмат стендында,Шахмай авылы, Үзәк урам, 47 нче йорты янында.

8. Әлеге карар аның басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Яңа Чишмә муниципаль районы
Шахмай авыл җирлеге башлыгы И.Г.Гаризов